**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» февраль, 2020 ел № 140

Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 20 августындагы 1137 номерлы карары белән расланган «2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 329-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль закон нигезендә 2007 елның 4 декабрендәге 4-ФЗ номерлы. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2021 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау» 1 нче кушымта белән тулыландырырга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Муниципаль районның
башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605397

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта
________________________________№

## 2021 елга республика бюджеты хисабына финанслау

| | | |
|---|---|---|
| Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | Ел дәвамында | 300900,00 |
| Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә түләүләр | Ел дәвамында | 49000,00 |
| Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчыларга-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен түләүләр | Ел дәвамында | 550000,00 |
| Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары командаларының хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | Ел дәвамында | 675300,00 |
| Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура чараларын үткәрүне оештыруга, блоклы модульле чаңгы базасын оператив идарә итү хокукында беркетүгә бәйле рәвештә «КСШ» МБУ муниципаль биремен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыруга бәйле | Ел дәвамында | 801170,00 |